СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**10.06.2026**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 34**

Зеленодольск шәһәре Советының 2018 елның 29 октябрендәге 209 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге ташламалы аренда түләвен билгеләү, торышы канәгатьләнерлек хәлдә булмаган файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын арендага бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

2002 елның 25 июнендәге «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 73-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәт белән нәтиҗәле идарә итү максатларында, Зеленодольск шәһәре Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск шәһәре Советының 2018 елның 29 октябрендәге 209 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге ташламалы аренда түләвен билгеләү, канәгатьләнерлек хәлдә булмаган файдаланылмый торган мәдәни мирас объектларын арендага бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктның өченче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын торышы канәгатьләнерлек хәлдә булмаган мәдәни мирас объектларына кертү критерийларын раслау турында» 2015 елның 29 июнендәге 646 номерлы карары белән расланган» сүзләрен «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25

июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 50.1 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Аукцион «Аренда шартнамәләрен, түләүсез файдалану шартнамәләрен, мөлкәткә ышанычлы идарә итү шартнамәләрен, дәүләт яисә муниципаль мөлкәткә карата хокукларның күчүен күздә тота торган башка шартнамәләрне төзү хокукына конкурслар яисә аукционнар үткәрү тәртибе һәм күрсәтелгән шартнамәләрне төзү конкурс рәвешендә торглар үткәрү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булган мөлкәт төрләре исемлеге турында» монополиягә каршы федераль хезмәтнең 2023 елның 21 мартындагы 147/23 номерлы боерыгы нигезендә үткәрелә»;

1.3. 7 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларын торышы канәгатьләнерлек хәлдә булмаган мәдәни мирас объектларына кертү критерийларын раслау турында» 2015 елның 29 июнендәге 646 номерлы карары белән расланган» сүзләре «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законның 50.1 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**